РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Карамалинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 8, Азнакаевский район,
с.Карамалы, 423301,
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 8нче йорт, Азнакай районы,
Карамалы авылы, 423301
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«13» ноябрь 2023 ел** **№ 5**

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Октябрь-Бүләк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. 2023 елның 23 ноябрендә 13.00 сәгатькә Октябрь-Бүләк авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Октябрь-Бүләк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә җибәрелгән мобилизацияләнгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Октябрь-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Октябрь-Бүләк авылында юлларны кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Октябрь-Бүләк авылында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне сак тотучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Октябрь-Бүләк авылында Һәйкәлне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Карамалы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык А.Р. Ногманов